ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 сентябрь 2024 ел

№ 5753

Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4666 номерлы Карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган һәм төзүчегә, техник заказчыга капиталь төзелеш объектын төзү проектын тормышка ашырганда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.2 статьясындагы 3-7 өлешләрендә каралган чараларны башкару өчен кирәкле документларның, мәгълүматларның, материалларның, килешүләрнең тулы исемлеген раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм аерым нигезләмәләре үз көчен югалтуны тану турында» 2021 елның 25 декабрендәге 2490 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4666 номерлы Карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5.1 пунктына, 5 пунктча үз көчен югалткан дип танып, үзгәреш кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов